КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 май г.Казань № 651

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 380 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 849 нчы; 2016 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2016 ел, 22 июль, 499 нчы; 2017 ел, 15 май, 285 нче; 2018 ел, 2 апрель, 201 нче; 2018 ел, 29 август, 731 нче; 2019 ел, 16 апрель, 296 нчы; 2019 ел, 20 август, 690 нчы; 2020 ел, 27 апрель, 336 нчы; 2020 ел, 13 июль, 578 нче; 2021 ел, 19 март, 147 нче; 2022 ел, 7 март, 204 нче; 2022 ел, 15 апрель, 356 нчы; 2022 ел, 3 июнь, 515 нче; 2023 ел, 6 март, 217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2027 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау,

янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның I бүлегендә:

«6 нчы рәсем. 2009 елдан 2012 елга кадәрге чорда гадәттән тыш хәлләрдә һәлак булганнарның саны турында мәгълүмат» юлыннан соң уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кризиска каршы идарәне үстерү адымнарының берсе – «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасын үстерү. Республикада 112 системасының эшләве Казан шәһәрендәге һәм Яр Чаллы шәһәрендәге чакырулар эшкәртелә торган ике үзәккә нигезләнеп гамәлгә ашырыла.»;

«6 нчы рәсем. 2009 елдан 2012 елга кадәрге чорда гадәттән тыш хәлләрдә һәлак булганнарның саны турында мәгълүмат» юлыннан соң унөченче абзацта «2013 елга эшләр планлаштырылды» сүзләрен «эш оештырылды» сүзләренә алмаштырырга;

«8 нче рәсем. 2008 елдан 2012 елга кадәрге чорда Татарстан Республикасында суда коткарылган кешеләр саны турында мәгълүмат» юлыннан соң җиденче абзацта «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 23 декабрендәге 835 номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәне, Коммерциягә карамаган максатларда кулланыла торган аз сыешлы судноларга дәүләт күзәтчелеге кагыйдәләрен һәм Коммерциягә карамаган максатларда кулланыла торган аз сыешлы судноларны классификацияләү һәм тикшерү турындагы нигезләмәне раслау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 18 сентябрендәге 820 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2002 елның 8 февралендәге 132 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасында су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» ярдәмче программасының I бүлегендәге 1 нче таблицадан соң сигезенче абзацта «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 23 декабрендәге 835 номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәне, Коммерциягә карамаган максатларда кулланыла торган аз сыешлы судноларга дәүләт күзәтчелеге кагыйдәләрен һәм Коммерциягә карамаган максатларда кулланыла торган аз сыешлы судноларны классификацияләү һәм тикшерү турындагы нигезләмәне раслау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 18 сентябрендәге 820 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2002 елның 8 февралендәге 132 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү» ярдәмче программасынд:

I бүлектә:

егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кризиска каршы идарә механизмнарының берсе – «112» кичектергесез оператив хезмәтләрне чакыру системасы (алга таба – 112 системасы). Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 март, б-574 нче боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында 112 системасы даими файдалануга тапшырылды.»;

егерме алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

II бүлектәге «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексында җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр хезмәтләренең, шәһәр инфраструктурасы хезмәтләренең килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү» бурычы чаралары» бүлекчәсенең 1 пунктындагы икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин